ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 5** **11 ноябрь 2019 ел**

«Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча халык җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябреннән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» № 131 Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставының 14 статьясына ярашлы

КАРАР КАБУЛ ИТӘМ:

1. 2019 елның 22 ноябренә 17.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле авылында, Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев урамы, 19 адресы буенча урнашкан Кәрәкәшле авыл мәдәният йорты бинасында үзара салым кертү соравы буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

“Сез 2020 елда, беренче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия сорауны хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Кәрәкәшле авылының Вахитов урамы юлына вак таш җәю(сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү).

«РИЗА» “КАРШЫ".

3. Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, һәм карар рәсми кабул ителгән көннән соң, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып

чыгарырга, 5 көн эчендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Кәрәкәшле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Хәмидуллина